

Мордовия районнарында бер матур традиция яшәп килә. Олы яшьтәге юбилярларны котлау. «Юлдаш» газетасы битләрендә дә юбилярларны котларга теләк белдерvчеләр байтак; укып киләсез. Бvген Дубенка районы Ломат авылында гомер итvче тыл хезмәткәре Зәйнәб Исхак кызы Алмаева турында сvзебез. Ана әле генә 90 яшь тулды. Шатландыра: ана туксанны бирмәссен әле.
Зәйнәб Исхак кызы Алмаева Дубенка районы Ломат авылында колхозчы Исхак Хайрулла улы белән Мәликә Сафиулла кызы гаиләсендә туа. Туган як табигатен яратып, кешеләрен vз итеп vскән кызга авыл тормышы бетмәс мәшәкатьләре белән кечкенәдән vк таныш.      Зур гаиләдә иртә эшли башларга туры килә vзенә. Хезмәт биографиясен 1940 нчы елны туган авылындагы «Кызыл юл» колхозында башлап жибәрә ул. Аннары «Партсъезд» колхозында торле эшләрдә хезмәт итә. Боек Ватан сугышы һәм аннан сонгы елларда илебезгә кvпне кvреп, зур vрләр яуларга туры килә. Халкы тырыша анын, шуна бvген рәхәт яшибез. Бу елларда Зәйнәб Исхак кызына ойдә дә ярдәмче булып олгерергә һәм халык белән бергә дә хезмәт куярга туры килә. Татар кешесе барысына да олгерә шул.
Тырышларны, булдыклыларны авыл жирендә кvзләп йориләр яшьтәшләре.
Шулай,1950нче елда, бәхетен очратып, киявгә чыга Зәйнәб Исхак кызы. Озакламый ике баласын, кvз нурларын тудыра - Нәимә кызын һәм Нәим улын. Кызганычка каршы, бәхете озын гомерле булмый Зәйнәб ханымнын. Оч елдан сон ире, ике балалы тормыш иптәшен калдырып, vлеп китә. Бар гомерен балаларына багышлый тол хатын. Хезмәттә генә тvгел, гаиләсендә балаларына ныклы терәк була ул. Ике баласын олы юлга тәрбияләп жибәрә. Ялгызына бик авырга туры килә, әмма ана бар эштә гаиләсе булыша. Бигърәк әнисенә рәхмәтле; ул беркайчан оныклары белән кызы Зәйнәбен ярдәменнән калдырмый. Зәйнәб Исхак кызы да тырыша - колхозда да эшли, vзенен хужалыгында йорт тутырып мал-туар да vстерә.
Бvген аны биш оныгы һәм тугыз оныкчыгы шатландырып тора. Үз йортында ялгыз яшәсә дә, улы белән кызы һәрвакыт янында; ярдәм итәләр, булышалар. Тиз арада килеп житәләр әниләре янына.
Авыр чакларында ана һәрвакыт жыр ярдәм иткән. Жыр ятратканга, кызы белән кияве Юбилей бәйрәменә татарча жыр бvләк иткәннәр. Бәйрәме белән котларга Дубенка муниципаль район Главасы урынбасары М.А.Маскаев, ГКУ «Социальная защита населения по Дубенскому району РМ» бvлек модире Е.В.Спиридонова, вакытлыча Ломат авылы администрациясе житәкчесе Р.Р.Абдрашитов һәм авыл Мәдәният йорты

хезмәткәрләре бүләкләре белән килгәннәр. Ломат авылының мәдәният хезмәткәрләре Зәйнәб Исхак кызына ана телендә кечкенә концерт та куйганнар.

**Наилә Насырова**